| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 Кырынды № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 10 ноябрендә 10 сәг 00 мин билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Су белән тәэмин итүне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тукай бистәсе, Тукай урамы, 17, ФАП янында үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.А.Нафиков